Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Иске Михайловка авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

07 ноябрь 2019 ел № 17

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Иске Михайловка авыл җирлегенең
Болгар-2 авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Болгар-2 авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2019 елның 24 ноябрендә, 12 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлегенең Болгар-2 авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:зират коймаларын алыштыру?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Болгар-2 авылы, Ирня урамы, 11А йорты.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Болгар-2 авылы, Ирня урамы, 11А йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Иске Михайловка
авыл җирлеге башлыгы И.М. Абдуллин